РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

**КАРАР**
**РЕШЕНИЕ**

15 сентябрь 2017ел № 7-24

**«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль вазыйфаларга һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 40 статьясындагы 7.4 өлешен, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12.1 статьясындагы 4 өлешен, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 9 өлешен, шулай ук Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы «Коррупциягә каршы тору мәсьәләләре» Указының 8 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль вазыйфаларга һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен расларга.

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән басылып чыга, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә халыкка (http://buinsk.tatarstan.ru) игълан ителергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үздә калдырам.

Буа муниципаль районы башлыгы,
Буа муниципаль районы Советы рәисе М.А.Җаббаров

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Советының 2017 елның 15 сентябрендәге
7-24 номерлы карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру һәм массакүләм мәгълүмат чараларына муниципаль вазыйфаларга һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Буа муниципаль районында җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче башка зат), контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазифасын биләүче затларга кагыла.

2. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында күрсәтелгән вазыйфаи затларның (алга таба - вазыйфаи затлары), аларның ирләренең яисә хатыннарының һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне урнаштыру процедурасын (алга таба - рәсми сайт) регламентлаштыра, шулай ук, әгәр федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән күрсәтелгән белешмәләрне урнаштыру һәм (яисә) массакүләм мәгълүмат чараларына тапшыру тәртибе билгеләнмәгән булса, массакүләм мәгълүмат чараларына аларны гарызнамәләренә бәйле рәвештә бастырып чыгару өчен белешмәләр бирү процедурасын регламентлаштыра.

3. Рәсми сайтта урнаштырыла һәм массакүләм мәгълүмат чараларына түбәндәге белешмәләрне бастырып чыгару өчен бирелә:

а) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукында булган яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының һәркайсының урнашу төре, мәйданы һәм иле күрсәтелгән исемлеге;

б) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының милек хокукындагы транспорт чаралары төре һәм маркалары күрсәтелгән транспорт чаралары исемлеге;

в) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының декларацияләнгән еллык кереме;

г) хисабына җир кишәрлеге, күчемсез мөлкәтнең башка объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр, оешмаларның устав (тупланма) капиталларында катнашу өлешләре, пайлар сатып алу буенча алыш-бирешләр башкарылган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр, әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы вазыйфаи затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә.

4. Рәсми сайтта урнаштырыла торган һәм бастырып чыгару өчен бирелә торган массакүләм мәгълүмат чараларына түбәндәгеләрне күрсәтү тыела:

а) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре турында, күрсәтелгән затларга милек хокукындагы мөлкәте турында һәм аларның мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында башка белешмәләр (әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән күрсәткечләрдән тыш);

б) ир яисә хатынның (иренең) яисә хатынының, балаларның һәм вазыйфаи зат гаиләсенең башка әгъзаларының шәхси күрсәткечләре;

в) вазыйфаи затның, аның хатынының (иренең) һәм гаиләнең башка әгъзаларының яшәү урынын, почта адресын, телефонын һәм аралашуның башка индивидуаль чараларын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

г) вазыйфаи затка, аның хатынына (иренә), балаларына, гаиләнең башка әгъзаларына караган яисә алардан файдаланудагы күчемсез мөлкәт объектларының урнашу урынын билгеләргә мөмкинлек бирә торган күрсәткечләр;

д) дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган мәгълүмат.

5. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләр аларны бирү өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көне эчендә рәсми сайтка урнаштырыла.

6. Әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне рәсми сайтка урнаштыру җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте (кадрлар хезмәте бүлекчәсе, кадрлар эше һәм муниципаль хезмәт мәсьәләләре буенча белгеч) белән (алга таба - кадрлар хезмәте) тәэмин ителә.

7. Рәсми сайтта урнаштырылган белешмәләр, шул исәптән алдагы елларда:

а) юкка чыгарылмыйлар;

б) вазыйфаи зат үз вазыйфасын биләгән бөтен период дәвамында ачык кулланылышта (рәсми сайтларда урнаштырылган) була.

8. Вазыйфаи зат анықланган белешмәләрне тапшырганда тиешле үзгәрешләр төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыру өчен билгеләнгән срок тәмамланганнан соң 14 эш көненнән дә соңга калмыйча рәсми сайтта урнаштырылган белешмәләргә кертелә.

9. Массакүләм мәгълүмат чараларыннан сорау килгәндә, кадрлар хезмәте:

а) сорау кергән көннән алып өч эш көне эчендә аның турында сорау кергән вазыйфаи затка хәбәр итә;

б) гарызнамә кергән көннән алып җиде эш көне эчендә әлеге Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән белешмәләрне бирүне, әгәр соратыла торган белешмәләр рәсми сайтта булмаса, тәэмин итә.

10. Кадрлар хезмәтенең муниципаль хезмәткәрләре әлеге Тәртипне үтәмәгән өчен, шулай ук дәүләт серенә кертелгән яисә конфиденциаль булган белешмәләрне Россия Федерациясе законнары нигезендә фаш иткән өчен җаваплы булалар.